# Аһәң чыңнары

**КАЗАН ШӘҺӘРЕ ЯҢА САВИН РАЙОНЫНЫҢ**
**«ТАТАР ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ 13 НЧЕ ГИМНАЗИЯ»**
**ГОМУМИ БЕЛЕМ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

# «АҺӘҢ ЧЫҢНАРЫ»

*«АҺӘҢ» ӘДӘБИ-ШИГЪРИ КЛУБЫНА ЙӨРҮЧЕ УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ*
*(ШИГЫРЬЛӘР, ХИКӘЯЛӘР)*

**Төзүче:** Алинә Илсур кызы Шәгәрәева - «Аһәң» әдәби-шигъри клубы җитәкчесе, Казан шәһәре Яңа Савин районының «Татар телендә белем бирүче 13 нче гимназия»нең туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучысы

**КАЗАН**
**2022**

## Кереш сүз

Туган телебез – бик моңлы тел. Телнең сыгылмалылыгы, матурлыгы, моңлылыгы шагыйрьләр, язучылар, җырчылар, нәфис сүз осталары өчен генә түгел, ул барыбыз өчен дә кирәк. Матур итеп сөйләшә белгән кеше матур итеп уйлый белә, матур итеп уйлый белгән кеше матур эшләргә омтыла. «Аһәң» әдәби-шигъри клубының тоткан кыйбласы – укучыларны иҗади фикерләргә, туган телдә камил, матур сөйләшергә өйрәтү аркылы татар телен саклау һәм даими кулланылышка кертү. Бүгенге вәзгыятьтә бик мөһим һәм актуаль мәсьәлә бу.

Бу уку елыннан безнең гимназиядә «Аһәң» әдәби-шигъри клубы эшли башлады. Әлеге клубта укучылар татарча әдәби әсәрләрне, татар халкының мәшһүр язучылары һәм шагыйрьләре иҗатын тирәнтен өйрәнә, татарча газета һәм журналларга даими күзәтү ясап бара. Иҗат итү калыплары, шигырь язу үзенчәлекләре белән таныша; образлы һәм фәлсәфи фикерләү серләренә төшенә; матур һәм аһәңле итеп сөйләргә өйрәнә. Клуб эшчәнлегендә лекция, практикум, тренинг, мастер-класс, иҗади остаханә, дискуссия форматлары кулланыла.

Клуб эшчәнлеге кысаларында шигъри кичәләр, әдәби-музыкаль кунакханәләр, театральләштерелгән тамашалар, гимназиякүләм конкурслар, әдәби марафоннар, юбиляр шагыйрьләргә багышланган шигъри флешмоблар һ.б. үткәрелә. «Аһәң» клубы эше барышында күренекле татар шагыйрьләре һәм язучылары, театр һәм эстрада артистлары, нәфис сүз осталары, журналистлар белән очрашуларга зур игътибар бирелә.

«Аһәң» әдәби-шигъри клубы чыгарган әлеге тәүге онлайн-җыентыкка укучыларның төрле дәрәҗәдәге иҗади бәйгеләрдә җиңү яулаган иң яхшы әсәрләре тупланды.

***Алинә Илсур кызы Шәгәрәева, «Аһәң» әдәби-шигъри клубы җитәкчесе, Казан шәһәре «Татар телендә белем бирүче 13 нче гимназия»нең туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучысы***

# Шигърият



**Кашапова Динә Рәис кызы, 16 яшь**

***Сагыну***

Белмим, әллә нидән бүген,
Болыт каплый күңел күгемне.
Яңгыр тамчылары түгел, күз яшьләре
Чылаталар  битне, күземне.

Нигә моңсу, нигә авыр миңа?
Йолдызларым, җавап бирегез.
Төн тып-тыныч, ай, йолдызлар балкый,
Нидән миңа болай күңелсез?

Назлы дустым, җилем, әйтче, нигә
Елмаясым килми һич кенә?
Бөтен җиһан, бар зур дөнья, нидән
Минем өчен бүген кечкенә?

Ай-сердәшем, бәлки син әйтерсең,
Кайдан килгән мондый ашкыну?
Ай дәшмәде, тик төн пышылдады:
"Күңелеңдә синең сагыну"...

***Халкым***

Туган җирем, туган телем, диеп,
Җырлар идем, моңлы көйгә салып.
Татар баласы мин, ә татарлар -
Чал тарихы булган бөек халык.

Милләтемне язмыш күп сынаган:
Суга салган, утка аткан, судан алып…

Сынау саен ныгый гына барган,
Түзем халык татар, сабыр халык.

Халкым, фашист төрмәсендә интегеп тә,
Дошманнарга баш имәгән горур халык.
Соң чиккәчә Ватанына тугры калып,
Сугышлардан кайткан җиңү алып.

Зарлы халык түгел татар, җырлы халык,
Гөрләп яши, җырга-моңнарга уралып.
Татарымның бер бөртеге мин, дип,
Әйтә алам күкрәгемә кагып!

Татар халкы уңган, юмарт, киң күңелле.
Туганнарча дуслар безгә күп халыклар.
Туган җирем, туган телем, халкым, диеп,
Горурланып әйтә алырлык хакым бар.

***Бөек Ватан сугышында һәлак булган шагыйрьләргә багышлап...***

Янәшәңдә үлем була торып,
Яшәү ямен данлап язгансың.
Ут эчендә килеш, күңелеңдә
Шигырь утын саклап калгансың.

Туган илгә керсез мәхәббәтең,
Тугрылыгың һәрбер җырыңда.
Иҗатыңа илһам кайдан алдың
Син дәһшәтле сугыш кырында?

Күңел түреңдәге җырларыңны
Күмә алмаган тау-таш тузаны.
Иҗатыңнан көч алгансың микән,
Үтә алырлык пуля буранын?

Кулда  корал, җанда шигырь белән,
Җиңү көнен якынайткансың.
Үлмәгән син, шигырьләрең белән,
Туган илгә, барыбер, кайткансың.

Син яшәрсең, шагыйрь, халкың хәтерендә,
Сүтелсә дә тагын күп еллар.
Үлемсезлек җыры булып яңгырыйлар
Яу кырыннан кайткан ул җырлар!

**Вәлиева Азалия Данияр кызы, 12 яшь**

***Ут афәте***

Табигатьнең иң рәхимсез
Дошманы нәрсә? – диеп,
Күзәтеп, уйлана торгач,
Алдым, ниһаять, белеп.

Давыл чыкса, бөтен нәрсә
Кубарыла, тузына.
Ә ул тынса, яңадан
Кайта ла үз урынына.

Кояш, көчле кыздырып,
Көйдерсә дә җир өстен,

Яңгыр явып, яңадан
Яшеллеккә ямь өсти.

Ә ут чаткысы чыкса,
Дөрләп кабынып китә.
Ямьле, яшел тирәлек
Каралып, көеп бетә.

Рәхимсез янгын сүнсә дә,
Матурлык кайтмый кире.
Кара күмер, көл өеме –
Янгынның калган җире.

Давылда, көчле җилләрдә
Бу куркыныч юк икән.
Табигатькә иң дошманы –
Кинәт чыккан ут икән.

Ут афәте – зур фаҗига,
Тиңләшми аңа берни.
Ут-шырпы – уен эш түгел,
Саксызлыкны кичерми!

***Тәмле төш***

Гаҗәп! Төнге күктә йөрим,
Айны күрәм бик якын.
Монда бик үк җылы түгел,
Уртача гына салкын.

Монда якты, бик тә якты –
Йолдызлар җем-җем килә.
Миңа карап, күзен кысып,
Матур итеп ай көлә.

Йолдызлар белән качышлы
Уйныйбыз рәхәтләнеп.
Ә ай үзе кул чаба,
Үзе бии дәртләнеп.

Уянып китеп, сикереп тордым,
Сузылып карыйм сәгатькә.
Озак йоклап, соңга кала
Язганмын ла мәктәпкә.

***Батыр Алиш***

Туган ягым шагыйрьләргә,
Язучыларга бик бай.
Алар арасында батыр
Абдулла Алиш та бар.

Алиш абый – якташым,
Көек авылы егете.
Туган илен азат итү –
Булган аның өмете.

Яуның беренче көненнән
Алиш киткән көрәшкә.
Батыр сугышкан, тырышкан
Дошманга бирешмәскә.

Мәкерле дошман, яралап,
Төшергән әсирлеккә,
Һәм үлемгә хөкем иткән,
Туган иленнән читтә.

Үзе үлсә дә, калды аның
Истәлеккә хатлары.
Җәлилчеләр булып ул да
Туган илен яклады.

Алиш үзенең хатларында
“Үләрмен мин” димәгән.
Үлгәндә дә батыр калган,
Дошманга баш имәгән.

Горурланам синең белән,
Сөекле туган илем.
Батыр, кыю Җәлилләрең,
Алишларың бар синең!

**Вәлиуллина Сәмирә Айдар кызы, 10 яшь**

***Тукайлы балачагым***

Балачак – гомер юлының
Әкияти юл башы.
Тукай абый әсәрләре –
Балачакның юлдашы.

Ул әсәрләр – бик кадерле
Һәм якын күңелебезгә.

Алар бездә, без – аларда
“Яшибез” үзебез дә.

Дәрес әзерләр урынга
Чыгар идем урамга,
Өйрәнергә теләмәгән
Акбай белән уйнарга.

Тик... Эш беткәч, уйнарга ярый!
Шунысын тотам истә.
Эш агачы һәрвакытта
Мул китерә җимеш тә.

Ә кайвакыт, ялкауланып,
Булышмасам әнигә,
Ачуланып яный әни,
Әйтәм, ди, Шүрәлегә.

Мин дә шулай янар идем,
Күрсәм теге каракны.
Су анасына үзем үк
Илтер идем таракны.

Кәҗә белән Сарыкның да
Аңлар идем моң-зарын.
Барып урап кайтыр идем
Көн дә Печән базарын.

Беләм, бу әсәрләр гомерем буе
Озата барачагын!

Иң күңелле, иң бәхетле

Тукайлы балачагым!!!

**Габдрахманов Адель Алмаз улы, 13 яшь**

***Халкым батырлыгы үлемсез***

Алсу таңнар күреп яшәү нинди рәхәт!
Айлы төннәр, ямьле иртәләр …
Тынычлыкны бозып, илебезгә
Илбасарлар бәреп кергәннәр.

Һәм башланган сугыш – кырыс сынау,
Көчлерәкләр җиңә сугышта.
Җиңелер дошман, әгәр ил уллары
Ватаны өчен тугры сугышса.

Илем халкы шул минуттан киткән
Ватан азатлыгын якларга!
Һичберкем дә гомерен кызганмаган,
Туган Җирен тырышкан сакларга!

Сугыш кыра барган, җирдә ятып калган
Илебезнең батыр ирләре.
Туган җирдән читтә – кайдадыр еракта -
Аларның ялгыз каберләре.

Сугыш дәвам иткән кайгы-хәсрәт белән,
Авыр айлар, еллар үткәннәр…
Яше-карты, түземсезлек белән,
Бөек Җиңү көнен көткәннәр

Җиңгән илебез! Үткән бу сынауны!

Үз уллары аны яклаган!

Алар тыныч, матур тормыш өчен,

Безнең өчен Җиңү яулаган!

Бу дәһшәтле сугыш онытылмас,

Тарих битләренә уелып калыр!

Халкыбызның бөек батырлыгы

Хәтеребездә мәңге сакланыр!

**Кашапова Диләрә Рәис кызы, 18 яшь**

***Төн***

Төн. Офыкта кояшның соңгы нуры сүнде,

Бакчаларда гөлләр йомган күзен.

Бары йодызлар һәм ак ай гына бизи

Караңгы күк йөзен.

Төн. Бар җиһанда тынлык хөкем итә,

Шау-шу тавышлардан тынып калган дөнья.

Искән җилдә агач яфраклары гына,

Күңелгә шом салып, кыштырдашып куя.

Төн. Күк гөмбәзендә яңа йолдыз кабынды,

Берсе сүнде шул ук мизгелдә.

Белдем: йолдыз булып яңа язмыш кабынгандыр,

Яшь күңелем шундый сизгер лә.

Төн. Җил дә тынды, әмма яфраклар

Үз телендә һаман серләштеләр.

Күңелемдәге уйлар һәм хыяллар
Бер табышмак булып берләштеләр.

Төн. Таңга әле ерак, табигать ял итсен,
Сихри төнгә кабат сокланыйм.
Җир тынычлыгын саклаган йолдызлар һәм
Мин генә йокламыйм.
Төн...

### ***Көзге яңгыр***

Табигатьнең ачы күз яшьләре
Булып ява көзге яңгырлар.
Бу яңгырда тәнне генә түгел,
Җанны өшетерлек сагыш бар.

Кулчатыр астына ышыкланып,
Ашыгабыз җылы өйләргә.
Көн буена баштан кичкәннәрне
Якыннарыбызга сөйләргә.

Булган кулчатырын да ачмый,
Кайберәүләр бара чыланып.
Чөнки өйдә тик ялгызлык көтә
Бушатырга күңел чоланын.

### ***Яз шәүләсе***

Көн бүген шундый матур,
Күк аяз, кояш көлә.
Саран гына булса да,
Бераз җылысы килә.

Зур боз сөңгеләренә

Вак тамчылар җыела.

Агач ботакларыннан

Тәңкә карлар коела.

Кыш әле бар көченә

"Мин хуҗа", дип лаф ора.

Тик кояш нурларында

Яз чыңы эленеп тора.

### ***Салкын җәй***

Җәйне кемдер урлаганмы,

Әллә качканмы үзе?

Җәй җәеләсе аланда

Сагышлы көзләр эзе.

Җаннар җәйгә сусаганны

Ул әллә белмәгәнме?

Үпкәләгәнме, югыйсә,

Үртәргә теләгәнме?

Тәүлекләр буе түгелә

Күкнең тишек комганы.

Күңелгә үк үтеп керә

Салкын яңгыр томаны.

Җил дә хәтта ачы исә,

Яфрак-таҗларны коя.

Игенчеләр басу-кырдан

Юеш уңышны җыя.

Август - инде җәйнең төне...

Мәрхәмәтле бул безгә!

Кояш назын бүләк ит бераз,

Кергәнче елак көзгә.

***Мөхәммәтгалиева Кәринә Раил кызы, 8 яшь***

### *Тукай мирасы*

Туган телем – Тукай теле,

Мин бит татар баласы.

Татар теле – туган телем,

Тукай абый мирасы.

Балачактан безнең дуслар –

“Шүрәле” һәм “Су анасы”,

Яраткан әкиятләребез –

Тукай абый мирасы.

Гомер буе безгә юлдаш

Тукай абый иҗаты.

Хәзинәгә тиң байлык ул

Тукай абый мирасы.

Халкым горурлыгы Тукай –

Милләтемнең кыйбласы.

Ил күгендә якты маяк –

Тукай абый мирасы.

# Чәчмә әсәр (хикәяләр)



**Гәрәев Искәндәр, 14 яшь**

***Табын күрке***

Иртәнге йокы никадәр рәхәт булса да, Кәрим бүген иртә уянды. Өйнең һәр почмагына таралган тәмле ис борынны кытыклады. Дәү әнисе иртә таңнан ук нидер пешерә бугай, мич янында кайнашканы ишетелә. Кәрим дә озак түзеп ята алмады: сикереп торып, урынын җыеп куйды да дәү әнисе янына ашыкты.

Көн дә кояш шактый югары күтәрелгәч кенә торып чыга торган оныгының бүген болай иртә торуын күреп, Гайшә әби гаҗәпләнде:

- Әбәү, улым, ничек болай иртә тордың әле син бүген?

- Йокым туйды инде, - дип кенә җавап бирде Кәрим, сер бирмәскә тырышып. Тик мичтә ни пешәсен белү теләге көчлерәк булып чыкты. Кәрим түзмәде:

- Дәү әнием, ә син нәрсә пешерәсең?

Сүз озайтып торырга артык яратмаган әбисе: “Табын күркен пешерәм, балам”- дип кыска гына җавап бирде дә эшен дәвам итте.

Бигрәк кызык кеше инде бу дәү әнисе. Оныгы белән гел ничектер серле сөйләшә ул. Әллә Кәримгә генә шулай тоеламы? Шулай да, дәү әнисе әйткән сүзләргә төшенеп бетмәде малай. “Табын” дигәнен аңлады ул, ә “күрке” дигән сүзне ишеткәне дә юк бугай. Кайда ишетсен инде, өйдә әти-әнисе гел русча сөйләшәләр. Башлангычны татар мәктәбендә укыган Кәримне, “бердәм дәүләт имтиханнарын барыбер рус телендә тапшырачаксың” дип, 5 нче сыйныфка рус мәктәбенә илтеп урнаштырдылар. Шуңа күрә җәйге каникулларын түземсезлек белән көтте быел Кәрим. Ярый шушы авылы, дәү әтисе белән дәү әнисе бар әле татарчасын онытмаска.

Кәрим ишегалдына чыкты. Аңа әле бик иртә шикелле тоелса да, ишегалды дөньясы, үз көндәлек мәшәкатьләре белән, бар көченә кайный иде инде. Чуар тавык, йомгак кебек йомры чебиләрен ияртеп, бодай бөртекләре сибелгән савыт тирәсендә маташа. Нәни сары чебиләр, әниләре артыннан

кабатларга тырышып, үзара мәш киләләр. Алар янына  артык якын килергә батырчылык итмичә генә, ләкин шактый эшлекле кыяфәт чыгарып,  урак койрыклы әтәч ишегалды территориясен барлап йөри. Кәрим, мавыгып китеп, шуларны озак күзәтеп торды. Кинәт яңгыраган чүкеч тавышы малайның игътибарын бакча ягына юнәлтте  Бакча рәшәткәсен кадаклап маташкан бабасын да күрми тора икән бит. Әһә! Менә кемнән сорый ул хәзер теге сүзнең мәгънәсен. Малай, тиз-тиз атлап, бабасы янына китте.

- Уяттыммы әллә үзеңне, улым? Шушы сынган рәшәткәне генә рәтләп алыйм дигән идем, - дип акланыбрак каршы алды аны дәү әтисе.

- Юк, дәү әти, син уятмадың. Мине бөтен өйгә таралган тәмле ис борынымнан кытыклап уятты. Табын күркен пешерәм, диде дәү әни. Ә мин ...  мин “күрке” сүзен аңламадым, - диде Кәрим, башын аска иеп. Бабасы, көлемсерәп кенә:

- Табынның яме булган иң төп ризык була инде ул, улым, табын күрке, - дип аңлатты, - Үзең уйлап кара әле нәрсә икәнен.

- Иң тәмлесе дә шулмы, дәү әти?

- Иң тәмлесе дә шул инде, улым.

Гаҗәп, нәрсә булыр икән бу? Кәримне баягыдан да көчлерәк кызыксыну хисе биләп алды. Иң тәмлесе нәрсә соң әле? Туңдырма! Аны пешермиләр, киресенчә, туңдыралар шул. Шоколад, конфетларны да мичтә пешермиләр. Анысын гына Кәрим дә белә, әле 5не генә бетерсә дә. Тагынниләр ярата соң әле ул? Чипсы дияр идең... Аны табынга куеп та тормыйлар бит... Кәрим тагын ниләр уйлап бетергән булыр иде икән, анысы билгесез. Ачык тәрәзәдән дәү әнисенең “ашарга керегез әйдә” дигән тавышы аның уйларын бүлде.

Кулларын әйбәтләп сабын белән юып, дәү әтисе белән өстәл янына килеп утырдылар.  Дәү әнисе,  ап-ак ашъяулыкка төреп, яңа гына мичтән чыккан теге “серле” ризыкны табынның нәкъ түренә китереп куйды. Дәү әтисе ашяулыкны саклык белән генә  сүтте. Бу – бер бөтен түгәрәк ипи иде. Дәү әтисе аны зур ихтирам белән генә алды да, күкрәгенә куеп, кисәргә кереште. Кәрим дәү әнисенең каш астыннан гына сирпелгән сынаулы карашын сизмәде, йотылып китеп дәү әтисен күзәтте. Бабасы  ипинең беренче телемен (кетердәп

торган кибән башын!) Кәримгә сузды. Оныгының нәрсә яратканын белә иде ул.

- Менә, улым, табын күрке шушы була инде ул, - диде бабасы, өстәл янындаурнашкан тынлыкны бозып, - Иң кадерле, иң тәмле, иң кирәк ризык, - дип дәвам итте.

Чыннан да, кичә кичтән ипиләре бетеп калган иде. Ипи булмагач, Кәрим ашын да юньләп ашамады, кашыгын тыгып бер-ике генә бутады да этеп куйды. Дәү әнисе кайнатып биргән, көн дә яратып эчә торган сөтне дә эчәсе килмәде малайның ипisez. Менә бит ә! Ипи – табында иң төп ризык икән бит. Ә Кәрим әллә ниләр уйлап бетерде.

- Ипинең кадерен белеп үс, балам. Игеннәр уңса, икмәк мул булса, тормышыбыз да бөтен булыр. Ачлык афәтен күрсәтмәсен Ходай, - дип өстәп куйды дәү әнисе.

Кулындагы кайнар ипи телемен әз-әзләп кенә кабып чәйни-чәйни, Кәрим дәү әнисе әйткән сүзләрнең мәгънәсенә төшенергә тырышты. Бөтенесен булмаса да, иң мөһимен аңлады малай: ипи – зур хөрмәткә лаек иң кадерле ризык!

**Хәлилова Айгөл, 13 яшь**

***Кыска гомерле бәхет***

Сентябрьнең иң матур бер көне иде бу. Әллә инде күңеле артык күтәренке булгангамы, Адиләгә бу көн шулай матур тоелды. Бүген Адиләнең күптәнге хыялы чынга ашты. Үткән уку елын әйбәт билгеләргә генә тәмамлаганы өчен, әти-әнисе аңа кесә телефоны алып бирделәр. Өр-яңа телефон! Аның классында әле берәүдә дә мондый әйбер юк. Инсафның иске телефонын санамаганда, әлбәттә. Ул аңа әтисеннән калган, иске инде ул. Уеннар да юк анда, рәсемнәр дә. Ә менә Адиләнең телефонында рәсемнәр бик күп, ике уен да бар. Классташлары шаккатачак! Шуны күз алдына китереп,

Адилә чын күңелдән елмаеп куйды. Ярата иде ул башкалардан аерылып торырга. Шуңа һәрвакыт уку әсбапларының да башкаларныкына охшамаганын алырга тырыша иде. Әгәр берәрсенең пеналы, я сумкасы аныкыннан  матуррак булса, аның кәефе төшә иде. Классташы Алсуга әтисе Мәскәүдән берьюлы берничә төсле яза торган ручка алып кайткач, Алсу Адиләнең чын “дошман”ына әйләнде дә куйды. Иптәшләренең аның янда түгел, ә Алсу янында бөтерелүен күтәрә алмады  кыз. Ул аны болай да өнәп бетерми иде. Алсу гел ” биш”кә генә укый. Укытучылар аны һәрвакыт мактап кына торалар ...

Ә менә бүген инде Адилә кабат игътибар үзәгендә булачак. Барысының да яңа телефонны тотып карыйсы, уеннарын уйнап карыйсы киләчәк. Кемгә бирер икән беренче? Ләйсәнгәдер, мөгаен. Ләйсән аңа һәрвакыт өй эшләре белән булыша бит. Димәк, Адиләнең “ударница” булуында аның өлеше дә бар. Руслан аңа үткән кышта тимераякларын төзәтеп бирде. Ул икенче уйнар. Фәнис тә ара-тирә йомышка ярап куя, ул өченче булыр...

Кемнәргә ничәнче һәм ни өчен телефонын уйнарга бирәсен уйлый-уйлый, кыз, мәктәпкә килеп җиткәнен дә сизми калды.  Класска керү белән, телефонын кесәсеннән чыгарды. Телефонда әле сим картасы да юк иде аның. Шулай да ул, шалтырату көткән йөз чыгарып, телефонын кулыннан да төшермәде. Күз ачып йомганчы, класстагы кызлар һәм малайлар аны уратып та алдылар. “Тотып кына карыйм әле... “,  “Мин дә карыйм инде...” кебек җөмләләр яңгырады класста. Адилә бәхетнең җиденче катында иде. Алсуның ручкасы да бу кадәр кызыксыну уятмаган иде бугай. Телефонда бер генә уйнап карар өчен, кызлар - малайлар аңа әллә ниләр вәгъдә итеп бетерделәр. Вәт бәхет булып куйды бит әле бу телефон. Адилә үзен чын патшабикә итеп хис итте. Аны барысы да ярата, ул барысына да кирәк. Ләкин мондый уңышның ясалма һәм вакытлы гына икәнен чамаламый иде шул кыз.

Кинәт класска “груша” Самат килеп керде (борыны нәкъ грушага охшаганга күрә аны барысы да шулай дип йөртәләр иде).

- Сез нишләп утырасыз монда? – дип гаҗәпләнде ул. – Хәзер математика урынына физкультура була бит.

Шул хәбәрне ишетү белән, класс, бертавыштан, “ур-ра!” дип кычкырды һәм кызлар малайларны, малайлар кызларны уздырып, барысы да спортзалга йөгерде (спортны бигрәк ярата шул аның иптәшләре). Адилә дә, аның яңа телефоны да онытылды. Этешә-төртешә йөгергән малайлар артыннан идәнгә төшеп чәлпәрәмә килгән яңа телефон ватыклары гына аунап калды.

**Хәкимова Гүзәл Зөлфәт кызы, 17 яшь**

***Ялкынлы чәчәкләр***

Мәликә урам ягыннан килгән тавышка сискәнеп китте. Ачык тәрәзәдән Айдарның тавышын танып, тәрәзәдән башын тыгып урамга карады ул.

- Әйдә, чыгасыңмы? Нишләп ятасың һаман өйдә? – дип кычкырды Айдар.

- Нишлим инде, бигрәк күп өй эше бирделәр бит, бу имтиханнар белән язның ямен дә күрми калабыз инде, - дип җавап бирде аңа Мәликә.

- Шуңа чакырам да бит инде сине урамга, әйдә, бер матур нәрсә күрсәтәм, - дип чакыргач, Мәликә түзмәде, чыкты.

Айдар белән сәлам алышкач, алар ташландык бакчаларга таба киттеләр. Шәһәр кырыендагы бистәдә яшиләр алар. Монда авылдагы кебек. Рәхәтләнеп саф һава суларга, сандугачлар сайравын тыңларга була. Иске йортларын калдырып уңайлы фатирларга күченеп киткән кешеләрнең ташландык бакчаларында җәй көне алмалар, чияләр өлгерә. Ул вакытта бала-чаганы бу тирәдән куып та чыгарып булмый.

- Нинди матур нәрсә турында әйттең син? – дип түзмичә сорады Мәликә сыйныфташыннан.

- Сабыр ит, өлгерерсең, - диде Айдар. – Бир кулыңны, егыла күрмә, - дип кызны кулыннан алды һәм алар ерганак аркылы сикереп чыктылар.

Моңарчы егетләр белән кулга-кул тотынып йөргәне булмагач, Мәликә ничектер оялып китте. Әмма Айдар кулыннан шактый кысып токткан иде, тартып ала алмады. Аннары да егет кызның кулын ычкындырмады. Шулай җитәкләшеп бакчага барып җиттеләр. Иске бакчага килеп керүгә Мәликә күкрәк тутырып тирән сулыш алды. Мондагы хуш исле татлы һавадан башлар әйләнеп аварлык иде. Ул авыз ачып сүз әйтергә өлгермәде, Айдар аңа:

- Менә, күр! Нинди чәчәк диңгезе монда! - диде.

Чынлап та алда ак күбек кебек шау чәчәккә чумган шомырт агачлары тезелеп киткән. Аллея кебек ике рәт утыртылган рәтләр арасында юлы да бар.

- Искитмәле! Нинди матур монда! Хуш исләре сулап туймаслык, - дип сокланды Мәликә. Минем монда килгәнем юк иде, мондый матур урын барлыгын белмәдем дә, - диде ул.

- Әйдә киттек, - дип Айдар Мәликәне аллея буйлап алып китте. Аннары йөгереп барып, шомырт чәчәге өзеп Мәликәнең чәчләренә кыстырды. Егетнең болай кылануы Мәликәне оялтса да, каршы килмәде. Агачлар арасында шулай озак йөрделәр. Сөйләштеләр, көлештеләр, тын калып сандугачлар сайравын тыңладылар. Балаларча шаярып, дусларча аралашып йөргән ике дусның йөрәкләре бер-берсен сүзсез дә ишетә, сүзсез дә аңлый башлаган иде. Моның чын һәм саф мәхәббәт икәнен ике яшүсмер аңладымы, юкмы...

- Агачның иң очына менеп, чәчәк алып төшимме сиңа? – дип сорады да, Мәликәнең җавап биргәнен дә көтмичә, Айдар агачка үрмәләп менеп китте. - Кирәкми, төш! Егыласың бит! – дип ялынган Мәликәне ишетмәде дә ул.

Айдарның агач башына менеп җиткәнен күргәч, кыз чынлап та куркып калды. Иң очыннан диярлек бер ботак чәчәк сындырып Айдар теш арасына кыстырып куйды. Сак кына төшәргә кирәк иде. Әмма ләкин биектән төшү - менү кебек җиңел түгел икән. Әйтәм аны, әбисе, “керер алдыннан элек чыгарыңны уйла” дип әйтә торган иде. Әбисенең бу сүзләрен әле генә аңлады бугай Айдар. Шулай да аста аның өчен куркып басып торган кыз алдында сер биреп булмый бит инде. Акрын гына төшә торгач, яртысына җитте. Ләкин инде күп калмады дигәндә Айдарның аягы таеп китеп, куллары белән агач

кәүсәсенә ябышып калды. Мәликә куркуыннан кычкырып җибәрде. Ләкин берничек тә егеткә булыша алмый иде шул. Айдар озак тотынып тора алмады, куллары белән агач кәүсәсен кочаклаган килеш шуышып төшә башлады. Аяклары җиргә басканда куллары сыдырылып, канга баткан иде Айдарның. Авыртуга чыдый алмыйча Айдар күзләреп чытырдатып йомды, ләкин аһ иткән тавыш та чыгармады. Мәликә күзләрен зур итеп ачып, курыккан тавыш белән:

- Бик авыртамы, Айдар? Нигә кирәк иде инде шулай эшләргә? Әйттем бит мин сиңа, егылырсың дип, - еламсырады.

- Кем егылды? Аягым таеп китмәгән булса... Ярар, борчылма, андый гына хәлләр була. Мә, бу сиңа, Мәликә! – дип чәчәген сузды. Мондый батырлык белән килгән чәчәк кыз өчен иң кыйммәтле бүләкләрдән дә кадерлерәк иде. Ап-ак шомырт чәчәкләре ара-тирә кызыл төскә буялып өлгергән. Айдарның кулыннан тамган кан гына буяп калмаган иде чәчәкләрне. Йөрәгендә кайнаган саф һәм кайнар хисләре шулай чәчәкләренә дә ялкын булып күчкән иде.

**Бәдриева Алинә Марсель кызы, 15 яшь**

***Әни улы***

Камилнең күзенә бүген йокы кермәде. Башка чакта сәгать кичке тугыз тулганчы ук караватка барып авасы гына килеп тора. Чөнки һәр көн иртәнге алтыда торып, мәктәпкә автобус, я трамвай белән бер сәгать тирәсе барасы. Укудан, тренировкадан арып-талып кичке бишләргә генә кайтып җитә. Әнисенең тырышлыгы белән ипотека кредитына алынган яңа ике бүлмәле фатирга күченгәч, аның элек укыган мәктәбеннән китәсе килмәде. Яңа мәктәпкә барып, үзенә кырын карап, сынап җәфалауларын теләмәде. Әнисе улын жәлләп, никадәр үгетләсә дә - юк. Егет сүзе бер булыр!

Ә менә бүген йокысын качырган уй баш миен кайната. Шәһәрдәге мәктәпләрнең берсендә - фаҗига! Унбиш яшьлек малай үз-үзенә кул салган: күп катлы йортның унынчы катыннан сикергән. Камил бу малайны үзе белән

чагыштырып карый да, кайгыга баткан әнисенең йөзен күзалдына китерә. Уфф, юк, юк! Алла сакласын! "Ичмасам, ник соң әти-әниеңне кызганмадың?", дип куя. Яраткан кызы ташлаган да, бу шулай аннан үч алган, имеш. Телевизордан да сөйләделәр бу хәл турында. Камилләрнең мәктәбе дә читтә калмады. Укытучылар тыз-быз чабышты, директор да линейкада бик озак сөйләде. Бик авыр булды бу минутларда Камилгә. Кызлар да бу көннәрдә элеккечә чыркылдап көлмәде, егетләргә бәйләнергә сәбәп эзләп чытлыкланмадылар. Бер укытучыга да баш бирмәс тәртипсез малайларга да бу көнне акыл керде шикелле тоелды Камилгә. Узган ел дәүләт имтиханын икелегә язган унберенче сыйныф малае үзен шулай әрәм иткән иде. Ул чакта да бик кайгырган иде Камил. Хәтерли әле, әнисе дә җитди сөйләшү үткәргән иде аның белән.

- Имтиханнарыңны бирә алмасаң, кайгырма, улым. Ничек тә бер җаен табарбыз. Менә минем югары белем дипломым юк та, начар яшәмибез бит. Эш яратсаң, ач булмассың. Ну, син шулай да укуыңны ташлама. Булдыра аласың син, башың бар, тырыш! Баллар җыя алсаң, университетка керерсең, улым. Булмаса, минем янда эшләп йөрерсең. Исән-сау кешегә эш бетми. Җан биргәнгә, юнь бирер Ходай, дәү әниең әйтмешли.

Шушы уйлары белән бутала-бутала шигырь ятлап, әнисенең эштән кайтканын көтә-көтә дәрес әзерләп утырган Камил сәгатькә карады. Унынчы ярты. Һаман кайтмый әнисе, соңга кала тагын. Мәктәптән кайткач, бер кисәк ит салып, бәрәңге шулпасы пешергән иде. Аны да кайнар килеш ашый алмый калды инде әнисе.

- Мин кайтканны көтеп, җыен юк-бар ашап, ач утырма. Аш пешер. Бер кыенлыгы да юк аның. Сәгать ярым-ике сәгать итең кайнаса, суганын, бәрәңге, кишерен саласың да, алары пешкәч, токмач салып җибәрәсең. Эшләгәнең минем өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен булыр. Мин синең яшеңдә Казанга бер үзем чыгып китеп урнаштым, - дия-дия әнисе аны аш пешерергә дә өйрәтте. Тикшереп, әйтеп торырга әнисе өйдә булмагач, ашы ташыган, кайнап бетә язган чаклары да булды. Кайнар шулпа чәчрәп кулы пешеп авыртып та

йөрде. Әнисе генә белми калды бу хәлләрне. Бераздан тозын да чамалап салырга өйрәнде, ашы ярыйсы гына тәмле килеп чыга башлагач, Камилнең үзенә дә пешерү эше ошап китә иде.

- Ресторанда шеф-повар булып китсәм әле! Танымассыз да абыегызны! - дип үзен киләчәктә затлы иномаркада йөри торган, модалы киенгән уңышлы, акчалы кеше итеп күз алдына китерергә ярата ул.

Хыяллары чынга ашармы, белмим. Ә әнисе аның өчен бик тырыша инде. Штукатур-маляр булып таңнан кара төнгәчә эштә булган әнисен бик кызганса да, берничек тә ярдәм итә алмый ул әлегә. Шул өй эшләрендә булышуын санамасаң инде. Ашарга пешерү генә түгел, күбесенчә идән юу, тузан суырту кебек эшләр дә аңа кушылган. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, ди әнисе. Эшләре, әнисе әйтмешли "шабашка" булганда, алар заказ бирүченең срокларына өлгерергә тырышалар. Бик тиз арада кирәк булганда, әнисе шулай ялны белмичә эшли. Яллары да сирәк була. Кеше төсле ай буе отпуск та алмый ул. Җәйнең җиләкләр өлгергән чагында берәр атна ял итеп ала. Эше тукталып торган арада ял итә, шунда да тыныч кына утырмый әнисе. Кул эше эшли, кемгәдер ярдәм итә, күршенең обоен ябыштырып чыга, туганнарның купкан, чатнаган стеналарын рәтләп, матурлап кайта. Эше озаграк табылмый торса, телефоны тынып торган араларда әнисе кайгыра башлый. Камил дә сизә инде. Яшәргә акча бетсә, каян табар әнисе. Табучы, ашатучы ул үзе генә бит. Шуңа күрә әнисен башка балалар кебек "миңа ул кирәк, бу кирәк" дип аптыратмый. Уку елы башында алынган шул бер киемнән йөрүеннән, кәрәзле телефоны да "отстой" булуыннан малайлар көлсә көләр. Үзе акча эшли башлагач алыр әле үзе теләгәнен. Әнисен дә матур киендереп, туннар бүләк итеп, җылы якларда ял иттереп, машинада йөртеп кенә рәхәттә яшәтер әле Алла боерса. Әлегә әнисе супермаркеттан пакет-пакет ризык ташыса, үсеп кеше булгач, Камил әнисе янына шулай тәмнүшкәләр төяп кайтыр. Классташ кыз Самира бервакыт аңардан "маменькин сынок" дип бөтен класс алдында көлгән иде. Никтер бу сүзгә Камил үпкәлисе килсә дә, үпкәли алмады.

- Әйе, мин әниемнең улы булу белән горурланам. Чөнки минем әнием

кайбер ир-атлардан да көчлерәк, нык характерлы, үрнәк әни. Ул берүзе тормышны алып бара. Ире ташлап киткәч, кайберәүләр кебек аракыга ябышмаган, башка ирләрнең муенына асылынмаган. Минем әни кебек әниләр бөтен кешедә дә юк ул! – дигәч көлүдән туктадылар. Класстагы һәр бала үзенекен уйлагандыр, күрәсең. Кызганычка каршы, әти-әниләр төрле була шул. Әнисеннән башка, авылдагы дәү әнисе, дәү әтисеннән башка якын кешесе юк Камилнең. Туганнары бар да, аларның да үз тормышы, үз кайгысы.

Әтисенең аларны ташлап киткәненә инде ничә ел икәнен дә хәтерләми. Хәзер сагынмый да, уйламый да инде әтисен. Кечерәк чагында әтисен сагынып, әнисенә үпкәләп, олыларның үзен "тулы булмаган гаиләдән" дип сөйләүләрен ишетеп, гарьләнеп елый иде. Хәер, класста "әтисез" бер ул гына түгел. Яшьтәшләренең моңа борчылмавын күреп, Камил дә тынычланды, әтисез үсүенә хурланмый башлады. Шулай да әтисе белән ирләрчә сөйләшеп утырасы, футбол тибәсе килә. Җәй көне бергә авылда печән чапкач, тирләп-пешеп кайнар чәйләр эчеп, үләнгә сузылып ятасы, зәңгәр күккә карап бергә планнар корасы, әтисен янына утыртып, машина йөртергә өйрәнәсе килә аның. "Малай актыгы!" дип берне сыптырып җибәрсә дә, үпкәләмәс иде. Әти кулы тимәгән малай була димени! Дәү әтисе бар әле ярый. Камил аны сагына, аның белән горурлана, иншаларын да аның турында яза. Дәү әтисе бик шәфкатьле, беркайчан да ачуланмый. Камил беренче тапкыр кулына тоткач, чалгы сындырган өчен дә орышмады, кеткелдәп көлде генә. Өч тәгәрмәчле, арбалы матаен сораусыз алып чыгып киткәне өчен дә тавыш күтәрмәде, "әй, улым, матаең белән чокыр төбенә тәгәрәп төшеп үлсәң, әниеңә ни дип җавап биргән булыр идем" дип көрсенде дә, өч-дүрт көн эндәшмичә йөрде. Ә Камилгә аның ачулануы кирәк иде, көчле тавышы белән куркытып, ирләрчә бер каты итеп акылга утыртуы кирәк иде. Иртәгесе дәресләр өчен рюкзагын дәреслек-дәфтәрләр белән тутырганда, кабызып куелган телевизорына карый-карый Камил үз-үзе белән сөйләште:

- Эх, әти, син булсаң, әни дә безне өйдә ашлар, өчпочмаклар пешереп көтеп торыр иде, ирләр эшендә йөрмәс иде. Мин дә бер нәрсә булса, ярдәм

сорап сиңа йөгереп килер идем. Кызык инде бу дөнья! Теге унынчы каттан сикергән малайның әнисе дә, әтисе дә булган, яхшы гаиләдән, бөтен кирәк нәрсәсе дә, айфоны да, компьютеры да, аерым бүлмәсе дә булган, әтисе машинада гына йөрткән, әнисе дә көне-төне эштә булмаган, кечкенә сеңлесен дә бик яраткан диләр - нәрсә җитмәгән икән аңа?! Нигә бу дөньядан, матур тормыштан туеп китте икән? Аңладымы икән нишләгәнен? Әнисенең кайгырып акылдан шашуын да уйламаган. Камилне шушы уйлар җәфалады.

Менә өй янындагы парковкага яшел "Матиз" кайтып туктады. Тәрәзәдән әнисенең машинасын күреп, Камилнең эченә җылы йөгерде. Бар да яхшы икән, әнә әнисе эштән кайтты. Әнә буяу чиләкләре, шпательләре, эш киемнәре белән тулган багажнигыннан ризык тулы пакетын алды да, "кечкенә подружкасын" пикелдәтеп бикләде. Хәзер ишекне ачып керер.

Менә тәмләп чәй эчәрләр дә, йокларга ятарлар. Чөнки күп вакыт әнисенең ашарга хәле дә калмаган була. Ятып йокларга гына. Аңарчы әнисе ак буяу чәчрәп каткан кулларын кат-кат юар, шпатлевка тузаны сеңгән киемнәрен кер машинасына ыргытыр. Камил су тулы чәйнекнең төймәсенә басты һәм ишек ачарга йөгерде. Көне буена аларның бергә күрешеп сөйләшергә аз гына вакытлары булып ала. Иртән өйдән чыгып киткәнче һәм кичен әнисе эштән кайтып йокларга ятканчы. Әнисенең улына, улының әнисенә булган яратуы, шушы биш минут эчендә бергә чәй эчүләре дә аларга җитә. Аларга шулай да бик рәхәт.

**Хөснуллин Нияз Ильяс улы, 14 яшь**

## ***Ракета***

Кирәк бит ә! Ну бу дәү әтине... Тапкан да бит кушаматның нindиен алырга. Кибеткә төшкән саен ачуы килә Әнисснең. Болай да ул анда төшәргә атлыгып тормый. Дәү әнисенең "улым, кибеткә төшеп менәрсең әле, бүген ипи килә торган көн" дигәнен ишеткән саен кашлары җимерелә, тәне казныкы шикелле була. Төшеп менүе аның өчен бер дә кыен түгел, югыйсә. Сәпиттә

генә (дәү әтисе “велосипед” сүзен никтер шулай әйтә) җилдерә ул анда. Ишектән килеп керүгә, кибет тулы карчык-корчыкның “Кем әле бу?”, “Кем малае соң бу?” дип төрле яклап сорау яудыра башлавына да түзәрлек (гәрчә, күзгә кадалган салам кылчыгы кебек эчне пошырса да). Менә шул яулыклы “прокурорлар”ның берсе аны танып ала да, авылның таш кибетен яңгыратып, “кәчтүм оныгы ич бу”, “кәчтүм кызының малае” дип тезеп тә китә. Кибет стенасының берәр кирпече төшеп китеп, тишек хасил булса, Әнис шул тишеккә кереп китәр иде, валлаһи.

- Әй лә, безнең урам малае икән ич, танымый да торам үзен.

- Кайчан кайттың, улым?

- Ни атлы соң әле син, исемең кем?  - дип сорау алу башлана. Күргән саен сорыйлар ла, әллә соң юри шулай кыланалар. Бу сорауларның һәркайсына Әниснең җавабы, өй эшенә бирелгән шигырь юллары кебек, күптән ятланган инде.

Менә бүген дә Әнис кибетче апа биргән ипиләрен тиз генә дәү әнисе теккән чүпрәк сумкасына шуыштырды да, кибет ишеген теге яктан ябарга ашыкты. Кәчтүм оныгы, имеш. Ул гаеплемени дәү әтисе “кәчтүм” кушаматлы булганга. Аның кушаматы түгел лә, нишләп аны шулай атыйлар соң әле? Әнис, ачуын бераз басарга тырышып, велосипедына атланды да өйгә таба юл алды. Дәү әтисенең йорты тау башына салынган. Шунлыктан кибет белән өй арасындагы маршрут “барып-килү” дип түгел, ә “төшеп-менү” дип шифрлана. Төшүе ансат кына үзе, ә кире менгәндә маңгайда тир тамчылары биешә башлый. Гадәттәгечә, Әнис бу юлы да шул бер үк шигырь юлларын кабатлап менә:

Тау башына салынгандыр безнең авыл...

Тукай бу шигырен нәкъ менә аларның йортына багышлап язгандыр кебек тоела Әнискә.

... Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул...

Чишмәсе юк югын, ләкин күле бар. Нәкъ тау астында гына Якты күл җәелеп ята.  Элек бу күлнең суы бик чиста булган, диләр. Кешеләр бу күлдән

хәтта эчәргә су алганнар. “Якты күл” дигән исеме шуннан калган, имеш. Ә хәзер күл тулы каз-үрдәкләр. Юньләп су коеныргга да, рәхәтләнеп балык тотарга да ирек бирмиләр каурыйлы “дошманнар”. Шулай да, иң рәхәте Әнисләргә. Дәү әнисе капка ишеген ачып кына төшереп җибәрә казларын күлгә. Кичен алып кайтканда да ерак барасы түгел. Куып менәсең дә, вәссәләм.

Шундый уйларга бирелеп, кайтып җиткәнен дә сизмәде Әнис бүген. Велосипедын гараж стенасына сөяп куйды да ишегалдына керде. Күзләре, бакча рәшәткәсе аркылы, кәефе бозылуга сәбәпче булган дәү әтисен эзләп тапты.

- Ну дәү әти инде, нишләп соң миңа һаман “кәчтүмнеке” диләр? Синең кушамат бит ул! – дип, зарларын сөйли-сөйли, бакчага атлады.

- Минеке шул. Ә соң син минем оныгым ла, - дип дәү әтисе көлде генә.

- Булсам бит, Кәчтүм буласым килми минем. Әнис мин. Исемем белән дәшсеннәр! – дип өзгәләнде Әнис. Малайның йөзе никадәр кызганыч булмасын, дәү әтисе кеткелдәп көлүен дәвам итте.

- Тапкансың хафаланыр нәрсә. Авылда шулай кабул ителгән инде ул. Бөтен кешенең диярлек кушаматы бар, улым, беләсең ич. Гадәти күренеш лә ул, авыл тормышының бер бизәге. Юк өчен кәефеңне төшермә, син нәрсә инде.

Анысы шулай. Дәү әтисе хаклы. Кушаматларның ниндие генә юк авылда: “беткән борын”, “куян”, “калай колак”, “саескан”, “телепузик”, “әтәч” һәм тагын әллә нindиләр. Кызык, кайдан килеп чыга икән соң да, ничекләр тагыла икән ул кушамат дигәннәре? Дәү әтисенең кушаматы тарихын Әнис яхшы белә. Дәү әтисе кечкенә чакта дәү әбисе аңа өр-яңа костюм сатып алганмы, әллә тектергәнме, анысы ул кадәр мөһим түгел. Дәү әтисе менә шул костюмны урамга киеп чыккан да “минем яңа кәчтүмем бар” дип бөтен кешегә мактанган. Шуннан “кәчтүм” кушаматы ябышып калган да үзенә. Кызлары, уллары - “кәчтүм кызы”, “кәчтүм малае”, инде менә хәзер аларның балалары “кәчтүм онықлары”. Ярый әле дәү әбисе кәчтүм урынына башка әйбер алмаган. Йөрер идең хәзер “ыштан” яки “оекбаш” оныгы булып. Чыннан да,

әнә башкалар белән чагыштырганда, ул кадәр куркыныч түгел бит әле аларның кушаматы.

Тау астыннан кадәр алып менгән ипи сумкасын өйгә генә кертеп җиткереп булмады. Сәпиттә эленеп торган сумканы дәү әнисе алып кереп киткән булса кирәк. Май урлауда тотылган карак песи кебек боек кына басып тора Әниснең "тимер дусты" гараж кырыенда. Малай быел буйга шактый үсеп китте. Күзгә аңа унөч тула. Буена күрә велосипеды шактый кечерәеп калды. Дәү әтисе ун яшьлегенә бүләк иткән иде аны. Әнис үз велосипедын бик ярата. Кечерәк булса да, ул аңа бик якын. Утыра да җилдерә генә. Куып тотып кара. Иптәшләре үзләренең зур велосипедлары белән дә еш кына аны куып җитә алмыйлар. Шул "тимер таена" атланып, көннәр буе җил белән куыш уйнап рәхәтләнә Әнис. Дәү әтисе: "Элек авылда малайларга ат җене кагылган дип әйтәләр иде, сиңа сәпит җене кагылган бит, малай", - дип шелтәли дә кайвакыт, Әнис соңга калыбрак кайтса. Авылның бер башыннан икенче башына чаба-чаба көн үтә дә китә. Ярый ла авыл бар әле! Шәһәрдә йөрерсең ди болай рәхәтләнеп. Шагыйрь Рәмиев белеп тә язган инде:

Әй, авыл, син мең шәһәрдән
Мең кабат ямьле вә хуш...

Әнис бу шигырьне бигрәк якын итә. Быел кыш көне шәһәрдә узган шигырь укучылар конкурсында, шул шигырьне сөйләп, Әнис беренче урынны алды. Сәхнәдә сөйләгәндә, авылны, аның киң урамнарын, гүзәл табигатен күз алдына китереп, илһамланып сөйләде. Ярatканнар да соң шагыйрьләр авылны! Нәкъ Әнис шикелле. Әллә инде Әнис нәкъ аларча "җаны, тәне белән" яратамы? Ничек кенә булмасын, Әнис фикеренчә, чын шагыйрь авылдан чыккан булырга тиеш. Авылның саф һавасын сулап, киң болын-кырларында йөреп, чишмә суларын эчеп үскән кеше генә шагыйрь була аладыр, мөгаен.

Авылның бер башыннан икенче башына таба велосипедта узышып йөрү генә туйдырды. Бүген Әнисләр чып-чын ярыш оештырырга булдылар. Кемнең велосипеды тизрәк тә, малайларның кайсы җитезрәк? Малайлар тау башына җыелдылар. Үзенең велосипеды ватык булып, соңгы вакытта малайларның әле

берсенә, әле икенчесенә тагылып йөргән Рушан тау астына төшеп китте. Аны судья итеп билгеләделәр. Кем велосипедында тау астына тизрәк төшеп җитәр? Секундомерлы япон сәгате белән мактанып алырга менә дигән форсат та чыгып куйды Рушанга, ниһаять (алайса инде кайчаннан бирле тагып йөри, ни күргән, ни сораган кеше юк). Үзара санашып, малайлар кем беренче, кем арты кем төшәсен билгеләделәр.

- Мин беренче төшәм дә, беренче булам да, - дип масайды Инсаф. Аның велосипеды иң яңасы, әле җәй башында гына алдылар.

- Арттан беренче булсаң гына инде. Көпчәкләреңне кара, бушап баралар бит, - диде Әмир. Бу сүзләр Инсафның кәефен төшерде булса кирәк. Һәрхәлдә, колак артына кадәр ерылган авыз бик тиз җыелды. Ачуны кемнәндер алырга кирәк иде. Инсаф Әнискә төртте:

- Кемнең арттан беренче буласы билгеле инде. Син үзеңнең кәрлә велосипедыңда тау астына кичкә кадәр төшеп җитсәң ярый ха-ха-ха...

- Малайлар дәррәү көлеп җибәрделәр. Әнис үпкәләмәде. Кызлар шикелле үпкәләп торсын ди тагын. Үзе дә кушылып көлде. Әйдә, көлсеннәр. Ышана ул үзенең тимер дустына.

Шул арада, тау астындагы “судья”, сызгырып, ярышка барысы да әзер икәнен хәбәр итте. Финиш сызыгы күренерлек итеп билгеләнгән, кулындагы секундомерлы сәгать батып баручы кояш яктысында ялтырап-ялтырап ала. Инсаф стартка басты. Рушан, бер кулына тоткан ак кепкасын өстән аска таба җилпеп җибәрүе булды, Инсаф, күз ачып йомганчы, таудан выжылдап төшеп тә китте. Тау башындагылар тын да алмый малайның төшеп җиткәнен карап тордылар. “Судья” вакытны билгеләп куйды.

Шул рәвешле, велосипедларның берсе артыннан икенчесе төшә торды. Тау астыннан мактанышкан, көлешкән тавышлар ишетелде. Менә Әнискә чират җитте. Рушан, ак кепкалы кулын аска төшереп, кузгалырга дип әмер бирде. Әнис, ишегалдында бәбкә я чебеш сагалап йөргән тилгән кебек, аска томырылды. Чыннан да, бу мизгелдә аңа иңнәрендә канатлар бар шикелле тоелды. Аһ, гөнаһ шомлыгы! Бу ни бу?! Тау уртасында ап-ак болыт... Казлар

бит бу! Дәү әнисенең казлары! Тезелешеп, өйгә кайтып киләләр. Кирәк бит ә! Башка чакны күлдән чыгара алмый җәфаланып бетәсең. Ә бүген үзләре кайтып киләләр. Кирәкле кишер яфраклары... Инде нишләргә? Тик бер генә чара кала: велосипедны борырга кирәк. Югыйсә, хәзер Әнис дәү әнисенең җәй буе үстергән бөтен казларын харап итәчәк! Малай, күзен чытырдатып йомды да, велосипед рулен уңга борды. Берни күрмәде дә, ишетмәде дә Әнис. Билгеле бер вакытка, гәүдәсе велосипедтан аерылып, һавада очканын гына сизде.

Иптәшләре йөгереп килеп тә җиттеләр. Әнис башын күтәрде. Маңгаенда дәү этисенең йодрыгы кадәр “шишка” барлыгын чамалады. Велосипеды әллә кайда калган. Ватылмаган үзе. Ярый әле ватылмаган. Казлар инде тау битенә менеп җиткәннәр.

Малайлар Әнискә торырга булыштылар. Йөзләрендә гаҗәпләнү, күзләре зур итеп ачылган. Үзләре һаман шул бер сүзне кабатлыйлар:

- Ну малай, очып та карадың син, ракетамыни...
- Точно, тач ракета сыман очтың син.
- Выж гына иттең, ракета...

Менә шулай итеп Әнискә “ракета” кушаматы ябышып калды. Ачуланмады Әнис. Киресенчә, ул үзенең яңа кушаматын яратты, хәтта горурланып йөртте. Үзеңнеке якын шул.

**Кашапова Динә Рәис кызы, 16 яшь**

***Батыр Артур***

Камыр батыр турындагы әкиятне мин әле дә яратып укыйм. Камырдан ясалган егетнең, шундый кыю булып, батырлыклар эшли алуына мин чын күңелдән сокланам. Әлбәттә, бу әкият кенә. Ләкин шул әкият минем күңел киштәсендә шактый гына зур урынны биләп тора. Гадел Кутуйның “Рөстәм мажаралары”нда абага турында әбисе сөйләгән әкият Рөстәмне ничек җилкендергән булса, минем халәт тә шуңардан бер дә ким түгелдер. Минем дә исемем Рөстәм. Ә этием хәрби кеше. Мин дә аның юлыннан китмәкче.

Иманым камил, хәрби булып, миңа киләчәктә менә дигән бер батырлык эшләргә җай чыгачак әле.

Тик бу хикәя минем турында түгел. Сүз балачак дустым Артур турында булыр. Без аның белән бергә балалар бакчасына йөрдек, мәктәпкә укырга да бергә кердек. Менә инде җиде ел, иңне иңгә терәп, бер сыйныфта укыйбыз. Артур артык беркатлы, юаш малай. Анысы да монысы, бигрәк акрын ул. Шул “пешмәгәнлеге” аркасында кушамат арты кушамат тагылып кына тора аңа. Җебегән, оеган, оешмаган, пешмәгән... Ниндиләре генә юк. Үпкәләми тагын үзе. Юаш кына елмаеп, күзләрен генә түбән төшерә.

Дустым булса да, миннән дә шактый гына “эләгә” аңа. Беренчедән, мин, нишләптер, аны аюга охшатам. Андый зур гәүдәле, юан да түгел ул үзе. Авыр хәрәкәтле, акрын кыймылдаучан булгангамы шунда... Үзем дә төгәл белмим. Тик кечкенәдән “аю” дигән кушамат бирдем мин аңа. Ул инде бу кушаматка шуның кадәр ияләште ки, “Аю”, “Аю Артур” дип эндәшүем исеме белән эндәшүгә тиң. Үпкәләми түгел, Артурның моңа хәтта исе дә китми. Дуслар ич без.

Ә бер көнне булган хәлләрдән соң, мин генә түгел, башкалар да аңа “аю” дип дәшә башлады.  Татар теле дәресендә кеше исемнәре турында өйрәндек. Укытучы Халидә апа һәр исемнең үз тарихы бар дип аңлатты. Һәр исем билгеле бер халыктан чыккан, һәм аның үзенә генә хас аңлатмасы бар икән. Вәт кызыксынып киттек бит. Сыйныфта нинди исемнәр бар, барысын да тикшерергә, тарихын эзләнергә тотындык. Кем китап актара, кем интернет киңлекләрен айкый. Башкаларныкы миңа караңгы, бигрәк тә үземнеке һәм дустымныкы кызыксындыра. Менә монда булды тамаша! “Рөстәм – бик зур, алып гәүдәле, борынгы иран халкында каһарман, пәһлеван” дигәнне аңлата икән. Исемемә җисеме туры килүен күр әле син! Батыр булырга теләвемне, батырлык эшләргә җыенуымны кайдан белгәннәр диген?! Ә Артур? Ышансаң – ышан, ышанмасаң – ышанма! Баксаң, “Артур” исеме кельт халкыннан килеп чыккан, “зур аю”, “кара аю” дигәнне аңлата икән. Менә сиңа мә! Әйтәм бит гел аюга охшатам үзен. Сыйныфтагы ерык авыз малайларга шул җитә калды.

Үзем, вакыт-вакыт, якын итеп кенә үртәсәм дә, дустымны кыерсытырга башкаларга юл куймыйм анысы. Кашларымны җимереп карау да җитте, колак артына кадәр ерылган авызлар бик тиз җыелды. Ник дисәң, мин сыйныфта гәүдәгә иң зуры. Быел бокс секциясенә йөри башлавым да башкалар өчен сер түгел. «Хук», «джеб», «свинг» кебек бокс алымнарын әле бик үк яхшы үзләштереп бетермәсәм дә, телем белән мин алар турында чын боксчыларны да уздырып сөйлимдер. Авыз суларын корытып тыңлап тора тегеләр. Шуңа күрә минем янәшәмдә Артурга кырын да караучы юк.

Кызганып та куям инде мин аны кайвакыт. Ни дисәң дә, ата тәрбиясе җитми аңа. Әтисез үсә ул. Әнисе аны ялгызы үстерә, ул әнисенә бердәнбер бала. Шуңа шундый йомшактыр инде ул, күрәсең. Менә минем әтием бар. Әйткәнемчә, ул – хәрби кеше. Аның каршында әзрәк җебеп, “тормозить” итеп торсаң, “ипи шүрлеге”ңә менеп төшәргә дә күп сорап тормый ул. “Егет булсаң, егет бул!” дип өйрәтә ул мине. Ә Артурның андый терәге юк шул. Физкультура укытучысы Дамир абый да каты бәрелми инде аңа шуңа күрә. Артур физкультура белән дус түгел, дип әйтеп булмый. Физкультура дәресен ярата ул. Бездән калышмаска да тырыша инде үзенчә. Тик Артур һәм “тизлек” төшенчәсе, математикача әйтсәк, кире пропорциональ. Аю бит инде, нишләтәсең. Дамир абый дәрес саен:

- Йөгергәндә тизрәк бул инде, энем. Бер аягыңны җирдән алганчы, икенчесенә эт ябыша, ләбаса, - дип тирги аны.

- Ябышмас, абый. Этләр белән дус мин, - дип, көлемсерәп кенә куя Артур.

Ә менә җитезлек бар үзендә. Канатка менү яисә турникта тартылу дисәң, хәтта минем борынга да чиртә Аю. Шул күрсәткечләрен исәпкә алып, йөгерү буенча нормативларны үти алмавына Дамир абый кайвакыт күз йома инде. Тик сыйныфтагы ерык авызлар, миңа ишеттермәгән булып, еш кына Артурны “камыр” дип үртиләр. Минем аларга түгел, ә кайвакыт “камыр”ның үзенә ачуым килеп куя. Егет кеше бит инде ул! Нигә шунда бераз тизрәк, усалрак, кыюрак булмаска?! Чынлап та, кабарып утырган камыр, диярсең. Камыр

батыр... Тфю, ниткән батыр?! Камыр Артур!

Узган җәйдә булган бер вакыйга балачак дустым турындагы фикеремне тамырдан үзгәртте. Эссе торган көннәрнең берсендә Артур белән су коеныргa барырга сөйләштек. Билгеләнгән вакыттан әле иртәрәк булса да, ул мыштырдаганны көтмичә, үзем аны кереп алырга булдым.

- Аю, әле һаман йокы симертәсеңме әллә? Әйдә, өнеңнән чык инде, җәй җитте, ләбаса! – дип барып керсәм, ни күзем белән күрим, Камыр Артур аш бүлмәсендә аш пешереп маташа. - Камыр, нишләвең бу? Кызлар кебек ашарга пешереп ятасың инде әллә? – дип гаҗәпләнүемнең чиге юк иде.

- Пешерсәм ни? Кызлар гына ашарга пешерә димени. Мин каникулда бит,

көн буе өйдә генә. Ә әнием эштән болай да бик соң, арып кайта. Ашарга пешерүнең ояты юк аның.

- Анысы шулайдыр да... Тик барыбер, минемчә, егетләр эше түгел инде ул. Менә мин бүген, иртүк торып, биш километр йөгереп кайттым, аннары гер күтәрдем.

- Ә мин, иртүк торып, өйне җыештырып алдым, идәннәрне юып чыктым. Тиз генә кибеткә барып, кирәк-яракны алып кайттым. Су коеныргa барасы булгач, ашны да пешереп куйыйм дим, чөнки көн үтәр әле анда.

Минем гомеремдә дә бу эшләрне эшләгәнем юк. Әни белән дәү әни эшли торган эшләр бу. Алар аны миңа кушмыйлар. Мин үзем дә әйткәнем дә, бу турыда уйлаганым да юк. Артур сүзен дәвам итте:

- Егетләр эше түгел, дисең син. Менә синең әтиең хәрби кеше. Аны хәрби задание үтәргә кая гына җибәрмиләр, аңа нинди генә шартларда булырга туры килмидер. Аның беркайчан да ашарга пешергәне юк, аларны һәрвакыт банкет өстәле көтеп торадыр дип уйлыйсыңмы?

Мин дәшмәдем. Хәрбилекнең, егетлекнең бу ягы турында һич уйлаганым юк иде. Камыр Артур мине тәмам аптырашта калдырды. Ниһаять, ул эшен тәмамлады, һәм без урамга чыктык.

- Көне шәп. Әллә соң баруышлый берәр туңдырма алып ашыйкмы? –

диде Аю.

- Әйдә соң, шәп фикер, - дип килештем.

Алган туңдырманы Аюга, минем әби әйтмешли, “әбизәтелне” ишегалдындагы яңа эскәмиягә утырып, ашыкмыйча гына ашарга кирәк. Мин исә каптым да йоттым. Бу һаман утыра әле нәүмизләнеп. Түзмәдем:

- Вәт камыр син, тәмам изелдең. Туңдырмаңны кояш сиңа караганда тизрәк ялый, ләбаса. Минем әби “иртә торсаң ит пешә, соңга калсаң бит пешә” ди еш кына. Бит тә пеште, күт тә пеште инде минем монда. Бигрәк кыздыра ла, тизрәк суга чумасы килә.

- Ә минем мәрхүм әби “тиз чапкан тиз арыр” дия торган иде.

- Әйтәм аны бик “тиз” чабасың син.

Шул инде ул, шәһәр әбиләре булгач... Каникул буе шәһәр тузанына батып ятарга туры килә. Менә ичмасам, кеше әбиләре кебек, авылда торса иде алар. Җәй буе ятар идең рәхәтләнеп алар янында авылда. Саф һава сулап, җиләк ашап, көннең көн буе су коенып...

Кинәт Артур сикереп торды. Һаман да ашап бетерә алмаган туңдырмасы кулыннан төшеп асфальтка чәпәлде.

- Рөстәм, - диде ул ярымпышылдап, - күрәсеңме?

- Нәрсәне? – дидем мин, моңа акаеп карап. – Кайчаннан бирле кояш астында ялтырап утырдык, кызу суктымы әллә инде үзеңә?

- Сулга кара. Өченче катка.

Башымны әкрен генә ул караган якка борып, карашымны бездән 10-15 метр чамасы ераклыкта булган йортка төбәдем, һәм күзләрем белән өченче катны эзли башладым. Көн бөркү булгач, барлык тәрәзәләр диярлек ачык. Ләкин берсендә чебен-черки кермәстән тәрәзәгә куела торган москит челтәре, җил беләнме, япьләреннән ычкынып, тик бер элмәктә генә эленеп, чайкалып тора. Ә иң аянычы, әлеге тәрәзә төбенә ике, я ике яшь ярымлык булыр, бер бала үрмәләп маташа иде. Йөрәгем жу итте, аяк астымда җир убылды диярсең.

- Ни..ни..чек инде шулай... Тә..тәрәзәне ничек шулай калдырырга бул...ла инде – дип кенә әйтә алдым тотлыга-тотлыга. Телем бәйләнде, тәмам

сүз әвәләмәслек булды.

- Алай да булгалый шул. Статистика буенча, илебездә ел саен 125-150 бала
шулай тәрәзәдән егылып төшеп үлә.

Нәрсә ди? Статистика диме? Кайдан белә ул боларны? Мин аны, гомумән, бу сүзне беләдер дип тә уйламый идем. Мин куркудан тәмам агарынган йөземне Артурга таба бордым. Ә ул тыныч иде. Башын шул хәерсез тәрәзәдән бер генә миллиметрга да читкә бормыйча, күзләре белән генә нидер эзли, нидер чамалый иде.

- Әй...дә...дә соң кыч...кыч...кырыйк...мы әл..лә? Яр...ддд..әмммгә чак...кк-ырыйк..кк бер...рәрсен...., - дия генә алдым көч-хәл белән. Авызымны тегеп куйдылармыни, телем һич миңа буйсынмый. Кулларымны бутап, кая карарга белмичә, аптырап тик торам.

- Тссс! Кычкырма! Кинәт сискәндереп җибәрерсең. Сак кына эш итәргә кирәк...

Дустымның тынычлыгы бераз миңа да күчә башлады бугай. Үземне кулга алырга тырыштым. Артурга пышылдап кына:

- Менеп җитәр дә, куркыныч икәнен абайлап, кире төшеп китәр, - дидем, акыллы фикер әйткән кыяфәт чыгарып.

- Син нәрсә, биологияне белмисеңме әллә? Ул бит әле сабый, моның куркыныч икәнен бөтенләй аңламый, үз-үзеңне саклау инстинкты тулысынча формалашып җитмәгән әле аның.

Бу сүзләре белән Артур мине бөтенләй “нокаут”ка җибәрде... Биологиядән “биш”ле минем үзе. Тик, әйтүе дә оят, теориядә белгәнне практикага күчерә белмим икән....

Мин бу “удар”дан һушыма килеп өлгергәнче, Артур инде теге йорт янында үсеп утырган агач төбендә басып тора иде. Агач нәкъ теге хәерсез тәрәзә турысында. Дустымның ниятен шунда ук аңлап алдым. Сабый (шуны гына көткән диярсең) тәрәзә төбенә тупырдап менем тә басты. Вакытның һәр секунды кадерле иде. Артур моны миннән дә яхшырак аңлый. “Эх” иткән

тавышы да чыкмады, аяк-куллары белән агачны кочаклап та алды, өскә таба шуышып менеп тә китте. “Аю” дигәнем күз алдында “тиен”гә әверелде дә куйды. Ботактан ботакка җитез генә сикергәләп, күз ачып йомганчы, ул теге тәрәзә турысына менеп тә җитте.

Кинәт нәрсәдер “шап” итте! Котым очып, әле һаман Артурдан аера алмаган карашымны җиргә ташладым. Бер генә япьтә эленеп, һавада чайкалып торган теге москит челтәре, ычкынып китеп, җиргә төшеп ярылган. Өченче кат дип сөйләнгәндә, моны ул кадәр биектер дип күз алдына китермисең. Менә моннан карап торганда, шактый ук биек икәнен аңлыйсың. Ә өстән караганда ничек икән? “Мин биеклектән куркам ахры” диген фикер баш миемне урталай ярып узды... Сабый өчен бу биеклектән егылып төшү җитди имгәнүләргә яки, җайсызрак килеп төшсә (Аллам сакласын!), үлемгә үк китерәчәк. Менә хәлиткеч мизгел!.. Бала, ап-ачык калган тәрәзә бушлыгыннан нәп-нәни кулын сузып, алга таба атлыйм дигәндә генә ... Артур, аяклары белән нык итеп агачның кәүсәсенә, бер кулы белән маймыл шикелле ботакка ябышкан килеш, бөтен гәүдәсе белән алга сузылып, икенче кулы белән җәһәт кенә баланы биленнән эләктереп алды. Бала аны-моны абайлап өлгергәнче, Артур аны, сак кына күкрәгенә кысып, әкрен генә аска таба шуыша башлады.

- Абау!!! Бу ни бу??! – дип кычкырган йөрәк өзгеч тавыш һәммәбезне кинәт сискәндереп җибәрде. Карасак, подъезд төбендә кулына сумкалар күтәргән яшь кенә бер хатын басып тора иде. Сабыйның әниседер дип аңладым. Куркудан йөзе агарынган, күзләре зур итеп ачылган бу хатын тораташ булып каткан. Ниһаять, һушына килепме, ни булганын аңлап җиткерепме, ул кычкырып елап җибәрде. Кулындагы сумкалар, “дыңк” итеп, җиргә тәгәрәделәр. Колакны ярып, нәрсәдер ватылган тавыш зеңгелдәде. Бала да, кискен тавыштан куркыпмы, әнисенең елаганын күрепме, үкереп елап җибәрде.

- Йә Ходаем!! Ничек болай соң бу??? Йоклап калган идең бит, улым!.. бердәнберем!.. Син йоклаган арада дип, кибеткә генә барып килдем бит йөгереп кенә...

Күз яшьләренә буылып, шашынып басып торган хатын кызганыч иде. Баласы егылып төшеп харап булган булса... Аһ! Андый кайгыны күрергә берәүгә дә насыйп булмасын! Менә Артур калтыранган аяклары белән җиргә басты. Елаган сабыйны, “Бетте, бетте, елама! Малайлар елак булмый алай” дип тынычландырырга тырыша-тырыша,  әнисенә илтеп бирде. Бирде дип, ана кеше Артурдан баланы тартып ук алды диярлек, һәм, елый-елый, кочагына кысты. Артур исә, җиңел сулап, гадәттәгечә, күзләрен аска төшереп, тыйнак кына елмайды да йөгереп китеп тә барды. Мин дә аның артыннан  иярдем. Инде бераз тынычлана төшкән хатын:

- Тукта, тукта! Улымны коткаручы батыр, кем соң син? Рәхмәт тә әйтеп өлгермәдем бит үзеңә... исемеңне дә сорамадым... Кем син? – дип кычкырып калды.

Мин, артыма борылып, бик канәгать һәм горур тавыш белән, дустым өчен җавап бирдем:

- Артур ул, Артур! Кам...ыр... Түгел! Батыр!!! Батыр Артур!

## Эчтәлек

### *Шигырьләр*

Сагыну ........................................................................................................ 4
Халкым ........................................................................................................ 4
Бөек Ватан сугышында һәлак булган шагыйрьләргә багышлап ....................... 5
Ут афәте ........................................................................................................ 6
Тәмле төш ........................................................................................................ 7
Батыр Алиш ........................................................................................................ 8
Тукайлы балачагым ........................................................................................................ 9
Халкым батырлыгы үлемсез ........................................................................................................ 11
Төн ........................................................................................................ 12
Күзге яңгыр ........................................................................................................ 13
Яз шәүләсе ........................................................................................................ 13
Салкын җәй ........................................................................................................ 14
Тукай мирасы ........................................................................................................ 15

### *Хикәяләр*

Табын күрке ........................................................................................................ 17
Кыска гомерле бәхет ........................................................................................................ 19
Ялкынлы чәчәкләр ........................................................................................................ 21
Әни улы ........................................................................................................ 23
Ракета ........................................................................................................ 27
Батыр Артур ........................................................................................................ 32

**Казан шәһәре Яңа Савин районының**

**ГБМБУ «Татар телендә белем бирүче 13 нче гимназия»**

**«Аһәң чыңнары»**

*«Аһәң» әдәби-шигъри клубына йөрүче укучылар иҗаты (шигырьләр, хикәяләр)*

**Төзүче:** Алинә Илсур кызы Шәгәрәева - «Аһәң» әдәби-шигъри клубы җитәкчесе, Казан шәһәре Яңа Савин районының «Татар телендә белем бирүче 13 нче гимназия»нең туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучысы

**Казан, 2022**

